**«МИН ДӨНЬЯНЫ ҮЗЕМ ИҖАТ ИТӘМ»**
**Әнвәр ШӘРИПОВ**
**иҗатына багышланган әдәби-музыкаль композиция**
*(өлкән сыйныф укучылары өчен)*

*Кичәнең башыннан ахырынача талгын гына көй агыла,*
*сәхнәгә ике алып баручы чыга.*

**1нче алып баручы:**

Мин дөньяны үзем иҗат итәм,
Үзем теләгәнчә,
Күргәнемчә ясыйм дөньяны
Бер Алладан илһам алып ясыйм,
Хыялымда ясыйм мин аны.

**2нче алып баручы:**

Мин дөньяны үзем иҗат итәм,
Җир тормышын,
Күкне, галәмне...
Иҗат өчен кирәк зирәклекне
Туган нигеземнән алам мин.

*«Мин дөньяны үзем иҗат итәм»*

**1нче алып баручы:** Хәерле көн, исәнмесез!? Безнең тамырлар туган-үскән җирдән башлана. Тамырсыз үләндә чери. Адәм баласы агачтан да, үләннән дә сизгеррәк. Дөнья иминлеге, ныклыгы да – тамырдан.

**2нче алып баручы:** Безнең бүгенге кичәбез героеның тамырлары Башкортстан Республикасыннан, ул – Әнвәр Мәгъдәнур улы Шәрипов.

**1нче алып баручы:** Бәхет туган җирдә генә, Туган җирдә ныклы тамыр җибәреп җитлеккән егет язмышы якты, матур, мул. Бүгенге кичәбез моның бер дәлиле булып тора.

Әнвәр Мәгъдәнур улы Шәрипов 1941 елның 9нчы октябрендә Ютазы районы Кәрәкәшле авылында туа.

**2нче алып баручы:** 1949 елда Кәрәкәшле урта мәктәбенә беренче сыйныфка укырга керә, урта белемне Лениногорск районы Зәй-Каратай мәктәбендә ала. Казан дәүләт университетының тарих филология факультеты татар теле һәм әдәбияты бүлеген (1965) шунда ук аспирантураны (1971),Ленинграддәүләт университетында докторантураны (1988) тәмамлый. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1978-1990 елларда Алабуга дәүләт педагогия институтында укыта һәм 1990 елда Чаллыга күченеп килә. Бүгенге көндә Чаллы дәүләт педагогия институты профессоры.

**1нче алып баручы:** Әнвәр Шәрипов – әдәбият галиме, шагыйрь. Борынгы татар әдәбияты мәсьәләләренә багышланган монографияләр, йөздә утыздан артык фәнни мәкалә һәм әдәбиятны укытуга багышланган методик кулланмалар авторы. Филология фәннәре докторы. «КамАЗ» төзелеше ударнигы, «Татарстан Республикасы атказанган укытучысы» (2005) дигән мактаулы исемнәргә лаек шәхес. 2009 елдан Энциклопедик Фәннәр Академиясенең хакыйкый әгъзасы.

**2 нче алып баручы:** Әнвәр Мәгъдәнур улы гомерен әдәбиятка, халыкка багышлаган шәхес.Ул – әдәбиятка гашыйк кеше. Сүз сәнгатен тирән яратуы аны әдәби иҗатка да рухландыра. Аның шигырьләре «Казан утлары», «Мәйдан», «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Шәһри Чаллы» кебек шәһәр, республика матбугатында басылып килә.

**1 нче алып баручы:** Әнвәр Шәрипов 2001 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Кем идең?» (2006), «Тукта, мизгел!» (2013) китаплары авторы. Шагыйрьнең шигырьләрен укыйбыз икән, аның барлык әсәрләренә дә хас бер үзенчәлекне тотып алу авыр түгел: ул – ихласлык.

*Укучылар чыгышы.*

**1нче укучы:**

Шагыйрь Тукай!
Туган халкым горурлыгы,
Милләтемнең бөек улы син!
Шигъри әсәрләрдә бирә алдың
Халкыбызның йөрәк җылысын.
Ерак гасырлардан килә торган
Халкыбызның күңел кылларын,
Шатлыкларын, кайгы-хәсрәтләрен,
Сызлануларын син бет җырладың,
Тарихында ниләр кичермәгән!
Күпме күргән татар милләте...
Бөтен татар халкын рухландырган
Иң кирәкле сүзне син әйттең!..
Юлдаш итә халкым Тукай сүзен,
Шатланганда, күңел тулганда...
Син халкымның бөек бер вәкиле –
Туган халкым бөек булганга!..

*«Тукай сүзе»*

**2нче укучы:**

Әй, мәһәбәт Идел!
Олы Идел!
Күңелемне минем беләдең.

Синең ярларыңа чыккан саен,
Яңа хисләр миңа бирәсең!
Авыр чакта, күңелем давыл чакта,
Мин табамын синдә тынычлык.
Уйнак дулкыннарың көлә-көлә
Юаталар мине: «Тыныч бул!»
Ә мин карыйм Идел өсләренә,
Сокланамын аның көченә.
Шунда сизәм: Идел тынычлыгы
Минем күңелемә күченә...
Әй, мәһабәт Идел!
Ераклардан килеп,
Басып торам синең ярыңда!
Минем кебек синнән тынлык эзләп,
Кемнәр килмәс әле тагын да!..
Кабатланмас шушы мизгелләрдә
Шундый теләк туа күңелдә:
Шатлыкларым калсын үземдә,
Кайгыларым аксын Иделгә!..

*«Әй, мәһабәт Идел!»*

**3нче укучы:**

Сабантуйга дәшер кошлар сайрый,
Җәйге җылы, талгын җил исә.
Сабантуйга дәшеп кояш балкый,
Болыннарда чәчәкләр үсә.

...Сөлгеләрне сөлгеләргә ялгап,
Их, урарга иде Җир шарын!
Күрсен иде дөнья Сабантуйлы
Татарстан дигән ил барын!

Тальян моңы дәшә Сабантуйга,
Җилкендерә һәрбер йөрәкне.
Сабантуйга дәшеп кызлар җырлый.
Яңгырата бөтен төбәкне.

**2 нче алып баручы:** Ул тормышны җыр-моңнанбашка күз алына китерә алмый. Композиторларыбыз В. Әхмәтшин, Р. Зарипов, М. Имашев, И. Нургалимов, В. Мироваев авторның биш дистәдән артык шигырьләренә көй яздылар. Алар арасында инде халкыбыз яратып өлгергән «Ага сулар» (Илгиз Закиров), «Әнкәй хатлары», «Соңлап килгән мәхәббәтем» (Рубис Зарипов), «Сабантуйлы Татарстаным» (Мәсгут Имашев) җырлары бар.

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Күпме еллар узган, ә без һаман
Ничек булган, шулай калганбыз.
Гомер язы – гүзәл яшьлектән без
Мәңге сүнмәс ялкын алганбыз.
*Кушымта:*

Маңгайга сыр, чәчкә аклар төшкән,
Әмма йөрәк әле тузмаган.
Еллар гына узган, еллар гына,
Ә бит безнең яшьлек узмаган.

Күк йөзендә икәү сайлап алган
Йолдызлар бит әле сүнмәгән.
Дистә еллар узган, әмма бездә
Яшьлек дәрте әле сүнмәгән.
*Кушымта.*

Җәйге иртәләрдә, бакчаларда
Сандугачлар моңы тынмаган.
Һәр минутның кадрен белеп яшик,
Яшәү рухы әле сынмаган.
*Кушымта.*

*«Еллар гына узган»*
*(Әнвәр Шәрипов сүз.,Илшат Нургалимов көе)*

**1 нче алып баручы:** Әнвәр Шәрипов үзенең бөтен күңел дөньясы белән укытучы кеше. Ул бу эшкә барлык белем-эрудициясен, бөтен көчен биреп эшли. Үз профессиясе белән горурлана.

**2 нче алып баручы:**

Мин яратам хәзер бу һөнәрне...
У-кы-ту-чы!
Нинди горурлык!
Минем алда киң, зур дөнья ачык.
Бу бит – бәхет!
Бу бит – бик зурлык!

**1 нче алып баручы**:

Тормыш өчен закон язылмаган, –
Һәркем яши үзе белгәнчә...

Шагыйрь әйткән сүзләр белән килешмичә мөмкин түгел. Ул җир йөзен, кеше күңелен үзгә бизәкләр белән үзе булдыра алганча баета.

*Укучылар чыгышы.*

**1нче укучы:**

Яшьлегемдә гүя яшен сукты –
Мин яр сөйдем...
Яшен утларында калып,
Ялкынында янып көйдем.
Яшьлегемдә гүя күк күкрәде –
Мин яр сөйдем...
Дәһшәтле күкрәү алдында
Сүзем әйтә алмас булдым.
Яшьлегемдә таулар иңрәде –
Мин яр сөйдем...
Мин үземне тау-таш актарырлык
Көчле батыр итеп тойдым.
Кинәт ялгыз калдым.
Ярым үзем белән
Алып китте бөтен дөньямны:
Эчәр суым, басар туфрагымны,
Күкрәк тутырып сулар һавамны...
Шул көннән соң ярты гасыр үтте,
Таба алмадым аңа тиңнәрне...
Күкрәгемдә һәркөн кабатлана
Шул ук яшен, Шул ук күкрәү,
Шул ук таулар иңрәве.

*«Яшьлегемдә гүя яшен сукты»*

**2нче укучы:**

Моңа кадәр җыр язмадым сиңа,
Көткәнмендер шушы минутны.
Син үзеңдә яхшы беләсең бит
Йөрәгемдә йөрткән ул утны.

Сиңа әйтә торган сүзләремне
Әйтмәсәм дә.
Аңлата бит минем бу күзләр...
Әйдә, язьйм әле.
Ишетелеп кенә калмасыннар,
Язылып та калсын бу сүзләр...

Сиңа булган хөрмәт-мәхәббәтем,
Син беләсең,
Йөрәгемдә һәрчак бит яна...
Бер-беребезне аңлап һәм тиң булып,
Гаиләне, туганнарны данга күмеп,
Эх, бер яшик әле шушы дөньяда!

*«Моңа кадәр җыр язмадым сиңа»*

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Ага сулар, ага сулар,
Сулар салкынмыни ул?
Иң беренче сөюләрем
Сүнәр ялкынмыни ул?
*Кушымта:*
Аккан суда күрәм төсле
Гомерем агышларын.
Айлар буе, еллар буе
Басылмый сагышларым.

Дулкынланып ага сулар,
Суга карап уйланам.
Ничә еллар узып китте,
Йөрәгемдә син һаман.
*Кушымта.*

Айлар ага, сулар ага,
Туктап тормый агымсу.
Яннарымда син булмагач,
Миңа һәрчак ямансу.
*Кушымта.*

*«Ага сулар»*
*(Әнвәр Шәрипов сүз., Илгиз Закиров көе)*

**2нче алып баручы:** Әнвәр Мәгъдәнур улы Шәриповның шигырьләре уйланырга этәрә. Ул гомеренең һәр минуты кадерен белеп, файдалы эш белән уздыруы хакында безгә бәян итә. Алай булмаганда мондый дәрәҗә, исемнәргә ирешү, иҗат белән шөгыльләнү мөмкин булмас иде. Шагыйрь шигырьләрендә туган ягы табигатен җыр-көйгә сала алуы белән бәхетле. Газиз әнкәенә, туган нигезгә багышлап шигъри юллар иҗат итүе аның шатлыкларын арттыра, туганнары, дуслары хөрмәтенә тезмә сүзләр таба алуы аны сөендерә. Ул моңлы, хыялый, гашыйк шагыйрь.

*Талгын гына көй агыла.*

**1нче алып баручы:** Автор хикәяләр, парчалар дә иҗат итә:
*«...Уйнагыз, уйнагыз миңа Бетховенны ...*
*Халык белән шыгрым тулы зиннәтле сарайда зур оркестр башкаруында атаклы «Героик симфония»не түгел, минем кечкенә генә бүлмәмдә, үз фортепианомда уйнагыз миңа «Айлы соната»ны... Ә мин, урындыгыма*

*ярымтаянып, күзләремне галәмнең чиксез ноктасына төбәп, бөек ашкынучының нерв җепләреннән ургылып чыккан тылсымлы авазларны җаныма-каныма сеңдереп, тын гына утырыйм; әле генә башымнан узган авыр фаҗигане кешелекнең әхлак кагыйдәләрен үлчи торган тәлинкәләренә салып, берәр нәтиҗәгә килергә тырышып карыйм. Аннан соң, чиксез вакытның комсыз агышы минем йөрәгемнән сихри музыканың соңгы авазларын рәхимсез рәвештә тартып алып бетергәч, Галәмдә яңадан тынлыку урнашкач, кузгалыйм да гасырларның серле томаны эчендә иңрәп яткан Урал таулары, Ык буйларына чыгып китим. Мәрхәмәтле Җир-Ананың кара туфрагындагы балачагымның әлегә кадәр дә суынып бетәргә өлгермәгән аяк эзләрен эзләп табыйм да, кипшенгән иреннәремне аларга тидереп, бөтен Галәм ишетерлек итеп пышылдыйм:*

*- Ул башканы-ы сөя-я-я... Ул башканы-ы сөя-я-я...*
*Уйнагыз, уйнагыз миңа Бетховенны...*
*Бәлки ул юатыр...»*

*«Уйнагыз, уйнагыз миңа Бетховенны... »*

**2нче алып баручы:** Кадерле тамашачылар. Бүгенге кичәдә шагыйрь иҗатына карата кызыксыну хисләре уята алганбыз икән, димәк, иҗат яңа бер ачыш, яңа бер дөнья булып киләчәккә ялганачак.

...Мин дөньяны үзем иҗат итәм
Үзем теләгәнчә,
Күргәнемчә ясыйм дөньяны.
Бер Алладан илһам алып ясыйм,
Хыялымда ясыйм мин аны.

Шагыйрьнең шигъри юллары белән үрелеп барган әдәби кичә укучылар күңелендә озак сакланыр.

**Файдаланылган әдәбият**

Хәлимов, З. Укутычы – галим Әнвәр Шәрипов: [туган көне белән котлап] /З.Хәлимов // Шәһри Чаллы. – 2005. – 28 октябрь.

Шәрипов, Ә. «Кем идең?»: шигырьләр / Ә. Шәрипов. – Казан: «Дом печати» нәшр., 2006. – 160 бит.

Ситдыйкова, Ә. Яңа китап белән очрашкач...: [шагыйрь Ә. Шәриповның «Кем идең син?» китабы турында] / Ә.Ситдыйкова // Шәһри Чаллы. – 2008. – 1 октябрь.

Журналның Әнвәр Шәрипов иҗатына багышланган махсус саны // Мәйдан. – 2011. – № 8.

Шәрипов, Ә. Тукта, мизгел!: шигырьләр, поэма, җырлар / Ә. Шәрипов. – Казан: «Ихлас» нәшр., 2013. – 256 бит.